Р.Р.Сәлахова
Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты (г.Казань)

# Татар телендә сүз ясагыч кушымчалар һәм сүзләр арасында омонимлык күренеше

Омонимлык - шактый катлаулы лингвистик күренеш. Әлеге күренешкә төгәл фәнни билгеләмә бирү өчен телнең грамматик һәм лексик элементларының үзара тыгыз бәйләнештә торуын исәпкә алу мөһим. Омонимлык барлыкка килү өчен аваз тышчасы тәңгәл яки бертөрле булган берничә тел берәмлеге яисә сөйләм кисәгенең составындагы кимендә бер морфемалары арасында мәгънә бәйләнешләре булмаска тиеш.

Татар телендә омонимлык күренеше лексик мәгънәгә ия булган мөстәкыйль тел берәмлекләре, төрле функция үтәгән һәм төрле мәгънәгә ия булган кушымчалар арасында, шулай ук сүзләр белән кушымчалар арасында күзәтелә. Сүзләр арасындагы омонимлык күренешен билгеләү әлләни авырлык тудырмый, чөнки алар лексик мәгънәгә ия. Кушымчаларның омонимлыгына килгәндә, хәл бераз катлаулана төшә, чөнки аларның мәгънәләре һәм функцияләре бары тик тамырга яки нигезгә ялгану аша гына ачыклана. Сүзләр һәм кушымчалар арасындагы омонимлык мөнәсәбәтләре шик тудырмый, чөнки алар икесе ике төрле тел берәмлеге һәм, безнең фикеребезчә, аваз тәңгәллеге аларны омоним дип билгеләү өчен җитәрлек җирлек була ала.

Омонимлык, нигездә ике яки өч аваздан торган ясагыч кушымчалар белән шундый ук аваз санына һәм төзелешенә ия булган булган тамыр сүзләр арасында күзәтелә. Мәсәлән:

**Ай*₁*** (исем). Күк җисеме. *Бик сагынсаң **ай**га кара, мин карыйм йолдызларга (җыр);*

**-ай₂** (фигыль ясагыч кушымча). Мәгънәсе: ясаучы нигездә күрсәтелгән тарафка хәрәкәт итү. *Кьн шулай књћелле, ќаннарны, йљрђклђрне якын**айт**а торган мђшђкатьлђр белђн њтеп тђ китте (М.Ђ.).*

**Ау*₁*** (исем). Тоту яки үтерү максаты белән кыргый җәнлек яки кош-кортны эзләү, эзәрлекләү эше. *Малиновкадагы соңгы **ау** картиналары күз алдына килеп, күңелдәге борчуларны яңарталар гына иде (А.Ш.).*

**-ау₂** (исем ясагыч кушымча). Мәгънәсе: ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен хезмәт итә торган предмет. *Җиргә бор**ау**ны батырганчы, буровойның үзен төзи-төзи дә өч-дүрт ай чиләнергә туры килә безнең якташларга (Ә.М.).*

**Әр*₁*** (исем). Тиргәү, ачулану, орыш. *Председательнең эше җиңелме әллә? Аның үзенә дә атлаган саен **әр** ишеттерәләрдер (А.Г.);*

**-әр₂** (фигыль ясагыч кушымча). Мәгънәсе: ясаучы нигез белдергән нәрсәгә әверелү. *Ул кешенең өстендә сус**әр**гән сары төстә казаки(Ш.К.).*

**Ым*₁*** (исем). Сүзсез генә нәрсә дә булса аңлату өчен ясала торган хәрәкәт, ишарә. *Тыңла, Җирәнем, хәзер яныңа чит илдән бер хәким керер. Аның ымнарына **ым** белән җавап бирерсең(Н.И.);*

**-ым**$_2$ (исем ясагыч кушымча). Мәгънәсе: ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәтнең атамасы: *Төтен һавага күтәрелмәсә, яв**ым** булыр (сынамыш).*

**Кер**$_1$ (фигыль). Берәр нәрсәнең эченә таба хәрәкәт итү, кая да булса үтү, берәр нәрсәнең чиген үтү;

**-кер**$_2$ (сыйфат ясагыч кушымча). Мәгънәсе: ясаучы тәгъбир иткән эш-хәрәкәткә сәләтле. *Атым ярсыган, кылычым үт**кер**$_2$, Син, ярсу атым, Әйдә, утка **кер**$_1$ (Ф.К.).*

**Кыр**$_1$ (исем) – урмансыз тигезлек, зур тигез ачык мәйдан. *Тулган ай үзенең моңсу нурларын урманнар, **кыр**лар өстенә чәчеп әкрен генә йөзә(Г.Ә.);*

**-кыр**$_2$ (сыйфат ясагыч кушымча). Мәгънәсе: ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәткә сәләтле. *Мин үзем дә җавапка бик тап**кыр** кеше, бер дә аптырап тормадым (Ф.Х.).*

**Сын**$_1$ (исем). Кешегә яки башка җан иясенә охшатып эшләнгән скульптура әсәре. *Бакчаның урта бер җирендә тәбәнәк кенә **сын** тора (С.С.);*

**-сын**$_2$ (фигыль ясагыч кушымча). Мәгънәсе: ясаучы нигез белдергән зат яки нәрсә дип санау. *Нђфисђ бу картныћ аћа ышанып бетмђвен, бала**сын**ып каравын сизђ (Г.Б.).*

**Чак**$_1$ (исем). Кеше билгеле бер урында яшәгән, булган яисә яшь аралыгына туры килгән вакыт. *Каз канаты ап-ак була, ир канаты ат була. Чит илләрдә йөргән чакта Бик сагынган **чак** була (җыр);*

**-чак**$_2$ (исем ясагыч кушымча). Мәгънәсе: ясаучы нигез белдергән әгъза өчен билгеләнгән җайланма. *Эт муенына энќе муен**чак** такмыйлар (мђкаль).*

Омонимлык рәтен дәвам итәрлек аваздаш тел берәмлекләренең саны ике белән генә чикләнмәскә дә мөмкин. Биредә сүзләр арасында күзәтелә торган омонимлыкны һәм мәгънәләре төрле булган, этимологик яктан да төрле чыганакка барып тоташа торган омоним кушымчаларны да исәпкә алу мөһим. Мәсәлән, **кер** берәмлегенең омонимлык рәтен түбәндәгечә дәвам итәргә була:

**Кер**$_3$ (исем). Юылган яки юылырга тиешле өс-баш киемнәре һәм тукымадан тегелгән төрле көнкүреш кирәк-яраклары. *Миңсылу **кер** тукмаклый (Һ.Т.).*

**-кер**$_4$ (фигыль ясагыч) Мәгънәсе: ясаучы нигез белдергән авазларга охшаш авазлар чыгару яки шундый авазлар чыгарып эш-хәрәкәт башкару. *Ике үгез үкерә-үкерә Күккә менә, Җиргә сикерә(Н.И.).*

Татар телендә омонимлык рәтендәге аваздаш берәмлекләрнең күплеге кушымчаларның күп вариантлы булуы белән дә аңлатыла. Мәсәлән, ***-кыр/-кер*** кушымчасының ***-гыр/-гер*** кебек вариантлары да бар.

***-гер**$_1$* сүз ясагыч: сыйфат ясагыч кушымча. Мәгънәсе: ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәткә сәләтле. *Фазиләгә, башка көнче хатыннар кебек, иренең кесәләрен актаруның да, артыннан шымчылык итүнең дә кирәге юк: гаиләсенең иминлеген кайгырта белгән хатынның иң зур коралы – сиз**гер** күңел(М.М.).*

***-гер*₂** мөнәсәбәт белдерүче: йөкләтү юнәлеше кушымчасы. Мәгънәсе: башка предмет яки затка юнәлгән һәм ул предметта теге яки бу үзгәрешләр кертә торган процессларны белдерү: ***кигер.*** *"Заһидә кебекләргә мондыйны ки**гер**ү – җинаять!" – дип уйлады кәефе кырылган Вилен(М.М.).*

***–гыр/-гер*** кушымчаларына аваздаш сүзләр түбәндәге мәгънәгә ия:

Гер₃ (исем). Металлдан эшләнеп, әйбернең массасын, микъдарын үлчәү өчен кулланыла торган төрле авырлыклар. *Алай-болай булса дип, кесәмә биш кадаклы **гер** тыккан, кирәкмәс йөк кенә булды(Ф.Х.).*

***ым*** кушымчасының исә, нечкә вариантына***(-ем)*** омоним булырлык берәмлекләр бары тик кушымчалар системасында гына күзәтелә, сүзләр арасында ***–ем*** кушымчасының аваз составына тәңгәл булган берәмлек юк.

***-ем*₁** (сүз ясагыч: исем ясагыч кушымча). Мәгънәсе: ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт өчен билгеләнгән әйбер. *Ки**ем** кешене бизђсђ дђ гњзђл итмђс (мђкаль).*

***-ем*₂** (сүз ясагыч: сыйфат ясагыч кушымча). Мәгънәсе: ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәт белән характерлана торган. *Бњтђннђрне кайгыртып та њз хђсрђтен сиздермђњче сабыр холыклы бу тњз**ем** кешенећ алдына тезлђнђсе килђ (Г.Б.).*

***-ем*₃** (мөнәсәбәт белдерүче: I зат тартым кушымчасы). Мәгънәсе: предметның беренче (сөйләүче) затка каравы. *Ышан, ил**ем**, шушы ант сугарды Йөрәг**ем**нең соңгы тибешен(М.Җ.).*

Омонимлык күренеше – телнең тарихи үсеш нәтиҗәсе. Билгеле булганча, ул әдәбиятта бик үзенчәлекле стилистик чара булып тора. Кушымчалар һәм сүзләр омонимлыгы поэзиядә, шулай ук халык авыз иҗатының шигъри әсәрләрендә еш очрый. Мәсәлән:

*Арыш, бодай бүләбез,*
*Аны болай бүләбез:*
*Тигез уңган, таза нык,*
*Таза ныкка – биш капчык.*
*Ялкау, чытык, мактан**чык***
*Мактанчыкка – буш кап**чык**,*
*Буш капчык, уеннан **чык**!*

*Әйлән, бәйлән, тәти куян,*
*Соры ян**чык**, Сал да **чык**!(саналмыш).*

*Артыбызда безнең ак куак,*
***Ак** куакка кунган ак буак;*
*Әтекәй кабәмнең өендә*
*Соңгы көнем инде мин кун**ак**(җыр)*

*Әтекәй, абзарың суырлы,*
*Митлә генә алып себер**че**;*
*Әтием-әнием бирәм дисә,*
*Җиңгигә әйтегез сөен**че**(җыр).*

Шулай итеп, омонимлык күренешен өйрәнү барышында телдәге һәр төрле тел берәмлекләрен исәпкә алу мөһим, бу үз чиратында, омонимлык рәтендәге берәмлекләр санын тагын да арттыра һәм әлеге күренешнең морфонология, морфология, синтаксис, сүзьясалышы кебек тел белеменең шактый катлаулы тармаклары белән бәйле күп кенә үзенчәлекләрен билгеләргә мөмкинлек бирә.

**Файдаланылган әдәбият**

1. Ђхђтов Г.Х. Хђзерге татар теленећ лексикологиясе. – Казан: Татар. кит. нђшр., 1979. – 130 б.
2.Ганиев Ф.А. Суффиксальное словообразование в современном татарском литературном языке. – Казань, 1974. – 232 с.
3. Ганиев Ф.А. Хәзерге татар әдәби теле. Сүзьясалышы. – Казан: Мәгариф, 2000. – 248 б.
4. Салахова Р.Р. Омонимичные суффиксы татарского языка. Казань: Gumanitarya, 2007. - 204 с.
5. Сәлахова Р.Р. Татар теленең омоним кушымчалар сүзлеге. Казан, 2010. – 54 б.
6. Сафиуллина Ф.С., Ризванова Л.М. Татар теленећ омонимнар сњзлеге.– Казан: Хђтер, 1997.– 96 б.
7. Татар грамматикасы: Өч томда. – Т.1. – Мәскәү: Инсан, Казан: Фикер, 1998. – 642 б.
8. Татар теленећ аћлатмалы сњзлеге. Љч томда. – Казан: Татар. кит. нђшр., 1977–1981.